ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел № 32/8

Авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен муниципаль милеккә аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 209-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булып, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан ирекле булган (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт өчен аренда түләве буенча ташламаларны түбәндәгечә билгеләргә:

1) арендалауның беренче елында аренда килешүе белән билгеләнгән аренда түләвенең 0% күләмендә;

2) арендалауның икенче елында аренда килешүе белән билгеләнгән аренда түләвенең 25% күләмендә;

3) арендалауның өченче елында аренда килешүе белән билгеләнгән аренда түләвенең 50% күләмендә;

4) арендалауның дүртенче елында аренда килешүе белән билгеләнгән аренда түләвенең 75% күләмендә.

2. Арендатор тарафыннан аренда килешүе буенча йөкләмәләрнең үтәлмәве сәбәпле, яки арендатор әлеге Карарның 1 пунктында каралган критерийларга туры килми башлаган очракта, авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән муниципаль мөлкәтне арендалау килешүен вакытыннан алда өзгәндә, муниципаль милектән фактта файдалану вакыты арендалау килешүендә билгеләнгән аренда бәясеннән 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев